МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

10.09.2021 Казан ш. № под-1172/2021

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомство бүләкләре турында» 2017 елның 19 апрелендәге ПУ-678/17 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомство бүләкләре турында» 2017 елның 19 апрелендәге ПУ-678/17 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2017 елның 2 октябрендәге под-1572/17 номерлы, 2018 елның 29 августындагы под-1253/18 номерлы, 2019 елның 14 октябрендәге под-1451/19 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның 1 пунктындагы бишенче һәм алтынчы абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының әлеге боерык белән расланган Ведомство бүләкләре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Яңа казанышлар өчен ведомство бүләге белән бүләкләү алдагы бүләкләүдән соң кимендә ике ел узгач кына мөмкин. «Мактаулы остаз» аерым хөрмәтләү билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә югарыда күрсәтелгән таләп кулланылмый.»;

1.8 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2.1.1 һәм 2.1.2 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

IV бүлегендәге беренче-дүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Кадрлар сәясәте бүлегенә (Л.С.Әмирова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Г. Һадиуллин